# НӘФАСӘТИ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘР АВТОРЫ

# АВТОР ЭСТЕТИЧЕСКОГО СВОЕОБРАЗИЯ

## ТАҖИ ГЫЙЗЗӘТ. КЕМ ИДЕ УЛ?

Таҗи Гыйззәт — татар әдәбиятында классик язучы булып танылган шәхес. Совет чорында аның әсәрләре татар урта мәктәпләре программаларына кертелгән иде. Алар шулай ук югары уку йортларының татар теле һәм әдәбияты факультеты студентлары тарафыннан да өйрәнелде. Т. Гыйззәт әсәрләре буенча куелган спектакльләр исә күп кенә театрлар сәхнәләрендә зур уңыш казанып килде.

Сәнгатьтә нинди проблемалар аның дикъкатен яулаган, нинди әдәби принциплар аның тарафыннан нигез итеп алынган, гомумән, татар драматургиясендә Т. Гыйззәтнең иҗаты нинди үзенчәлекле сыйфатларга ия? Максатым — шул сорауларга җавап бирү.

*Беренче үзенчәлек.* Т. Гыйззәт әсәрләре татар халкы тарихы һәм ул үзе яшәгән чорның нәфасәти* шәкелдәге елъязмасын тәшкил итә.

Мин нәрсәне күздә тотам соң? Елъязма 1861 елда башлана. Ул үзенең тарихи чагылышын башлыча «Наёмщик» драмасында таба. Бу әсәрнең сюжеты татар крестьяннарының шушы елда чыккан патша манифестына мөнәсәбәтен, аларның нәфрәтле күтәрелешен күрсәтә.

«Ялкын» («Фәрхиназ») татар крестьяннарының 1878 елда патша хакимияте тарафыннан халыкның дини хисләренә кагыла торган тәртип урнаштыруына каршы баш күтәрүен чагылдыра.

«Чаткылар» драмасында 1906—1907 елларда халык массаларының патша министры Столыпинның җир реформасына каршы күтәрелеше гәүдәләнә.

Аннан соң «Ташкыннар» трилогиясендә 1914 елда башланган Беренче бөтендөнья сугышы, 1917 елдагы ике

* *Нәфасәт* — эстетика; нәфислек, нечкәлек, сәнгатьчәлек.

революция чорында татар крестьян массаларының яшәеше, шушы тарихи вакыйгаларда ничек катнашуы тасвирлана.

Ә менә «Бишбүләк» әсәрендә татар авылында Гражданнар сугышының утлы вакыйгалары сурәтләнә, ике капма-каршы якка бүленгән сыйныфларның низаглы бәрелешләре гәүдәләнеш таба.

Соңрак татар авылында күмәк хуҗалыклар төзүгә багышланган унлап әсәр, шулар арасында 1930 елларда татар театрлары сәхнәләрендә шаулап барган «Мактаулы заман», аннан соң Ватанны саклау темасына язылган «Таймасовлар», «Төнге сигнал», «Изге әманәт», «Чын мәхәббәт» һ. б. әсәрләре куела.

Ватан сугышы тәмамланганнан соң, халкыбызның социаль-икътисади тормышында катлаулы проблемалар барлыкка килә. Халык массалары бу каршылыклы шартларда үзенең чыдамлылыгын, Ил-анага тугрылыгын саклап кала. Шул елларда Таҗи Гыйззәт берничә әсәр, «Безнең авыл егете», «Алсу таң» һ. б. пьесаларын иҗат итә. Шул исәптән беренче пәрдәсен тәмамлаган тәкъдирдә үз өстенә чиновниклар тарафыннан дөнья хәтле тәнкыйть сүзләре ишетәчәк юньсез авыл райкомы секретареның «хикмәтләрен» тасвирлауга багышланган «Туктаровлар язмышы» драмасын да...

Биредә шундый сорау туарга мөмкин: Таҗи Гыйззәт телгә алынган йөзьеллыкны алдан билгеләп, бөтен иҗади хезмәтен шушы араны конкрет әсәрләр белән «тутыруга» багышлаганмы? Яисә монда башка ниндидер этәргеч моментларны күрергә кирәкме?

Соңгысы дөресрәк булыр. Беренчедән, әти үз заманындагы кайбер язучыларыбызның ханнар, шаһзадәләр тормышыннан алып язган әсәрләрен үз иҗаты өчен тәнкыйть күзлегеннән бәяләде. Аның карашынча, әсәрдә язучы үзенең бар сәләтен, талантын «әллә кайда», «әллә кайчан», «әллә нинди» бәндәләр кичергән тормышны тасвирлауга сарыф итә икән, ул инде сәнгатьнең төп вазифасын аңлап җиткерми булып чыга. Яисә (аңлаган тәкъдирдә дә) конкрет чынбарлыктагы социаль каршылыкларны күрсәтүдән баш тартып, үз юлын читтәрәк, хәвефсезрәк төрдә күрә.

Икенчедән, татар халкының тарихы, башка халыкларныкы кебек үк, төрле этаплардан, вакыйгалардан

тора. Аларның кайберсе халык яшәешендә якты маяк ролен үти.

Таҗи Гыйззәт тә нәкъ менә үз халкы тарихының мөһим, хәлиткеч роль уйнаган мизгелләренә игътибар итә. Шул сәбәпле әсәрләрендә халыкның гаделлек өчен барган көрәшләрдә иң көчле талпынулары гәүдәләнә, халык арасыннан аның батыр, иң тәвәккәл, иң фидакяр шәхесләре мәйданга чыга.

Чыннан да, аның әсәрләре татар халкының узгандагы тормышын сәнгати шәкелдә колачлап ала. Алар күк йөзендәге Киек Каз Юлы йолдызлары кебек җемелдәп торалар, асылташлардай, үзләренә җәлеп итүдән туктамыйлар.

*Икенче үзенчәлек* шунда ки, Т. Гыйззәтнең күпчелек әсәрләренә тулы канлы реализм хас.

Татар драматургиясендә мин шартлы рәвештә ике төрле реализмны аерам. Берсе — көнкүреш реализмы.

Сюжет менә нәрсәдән гыйбарәт: ике яшь йөрәк (кыз белән егет) бер-берсен яратыша. Ләкин аларның кавышу юлында — киртәләр. Йә кызның ата-анасы ризалык бирми, йә егетнекеләр риза түгелләр. Шуның өстенә кызны үзенеке итү нияте белән башка бер егет киртә корып маташа. Ләкин бу киртәләр алып ташлана, ике мәгъшук бәхеткә ирешә... Дөньяда мондый хәлләр буламы? Әлбәттә, була. Ләкин чын, тулы канлы реализм өчен ул гына җитми...

Хәлбуки сәнгать әсәре ул — чынбарлыкның образлы чагылышы, ә чынбарлык егет белән кызның бәхеткә ирешүенә генә кайтып калмый. Ул гаять катлаулы. Һәм реализм әсәре чынбарлыкны шул барлык катлаулылыклары белән чагылдырырга тиеш.

Т. Гыйззәтнең «Чаткылар» драмасын алыйк. Бу әсәрдә дә ике яшь кеше — Гаяз белән Мәһисәрвәр — берберсен яратышалар. Әмма арага Сабир бай тыкшына. Ә Мәһисәрвәрнең атасы — староста Әтүтән Дәүли — аңа ярарга тырыша. Шул гынамы? Түгел шул. Ике яшьнең бергә кушылу нияте алар яшәгән чынбарлык шартлары чолганышында тормышка ашырыла. Башлыча вакыйгалар татар авылында, гомумән Россиядә, патша министры Столыпин җәнапларының җир реформасын тормышка ашыру чорында бара. Биредә без крестьяннарның ясак түләү вазифасына бәйле мөнәсәбәтләр белән танышабыз. Ә халык җилкәсен кимерүче Сабир бай, үзенең

өендәге хезмәтче кыз баланы алдау белән бергә, аклану өчен аның атасы Тимай картка хәер сәдакасы ташлап, аны юату өчен хәйлә юлына басканын күрәбез. Шундый ук юл белән ул үз кардәше Гыйльмениса карчыкның иманасын алдап ала. Әсәрдә «зәкяткә бирү», «милекне закладка кую», «недоимка» өчен крестьянны нинди нәтиҗәле карар көткәнлеге, халык исеменнән имзалар җыю күренеше, байгураның ришвәт биреп җәзадан котылуы, ачуы купкан халыкның «земский начальник»ны куып җибәрүе һ. б. гаярь күренешләр, «староста», «пүнәтәй», «следователь», «адвокат», «тылмач» кебек затларның крестьян тарафыннан телгә алынуы — болар барысы да аны коры схема булудан азат кыла, укучыны конкрет халыкның конкрет шартларда яшәгәнлегенә ышануны тәэмин итәләр.

*Өченче үзенчәлек* — Т. Гыйззәт әсәрләрендәге тел байлыгы, образлы әйтемнәр, әсәр тукымасына табигый рәвештә кереп урнашкан милли йолалар, гадәтләр. Әти татар диалектларын бик әйбәт белүчеләрдән иде. Беренче тапкыр танышкан кешегә дә ул, син фәлән яктан икәнсең, дип, мөһерен баса иде. Татар телен ватып, бозып сөйләүчене өнәмәде. Мин үзем унике ел Совет Армиясе сафларында хезмәт иткән кеше, Казанга кайткан чакларымда, әти белән сөйләшкәндә, тел ягыннан җаваплырак булырга тырыша идем. Килешмәгәнрәк сүзләр ычкындырганда, әти миңа: «Дөрес сөйләмисең, улым. Бездә менә шулай әйтәләр», — дип, мине төзәткәли иде.

Халык җырлары да аның зиһененә җиңел урнаша иде, чөнки бу төр иҗатка төгәллек хас. Ә танылган, ләкин ялган пафоска тартышлы шагыйребезнең:

Безнең болын яшел чирәм,
Колхоз аты ашасын.
Ул яшәсә, без яшәрбез,
Ленин юлы яшәсен, —

дигән шигыреннән ачыну белән көлә иде. Чөнки, чыннан да, «ул яшәсә» дигән сүзләрдә Ленин юлымы яисә колхоз атымы яши?

Әти халыкта туган җырларга зур кызыксыну белән карый иде. Бервакыт минем тормыш иптәшем Фирдәвеснең авылдан чыккан апасы безгә үзенең танышын ияртеп

килгән. Өстәл янына әти дә чыкты. Менә Сәмигулла абзый җырлап җибәрде. Җыр өстенә җыр! Ә әти нишли диярсез? Тыңлый бит, кабат-кабат җырлавын сорый. Күрәсең, әти әлеге абзыкайның җырлавын профессиональ яктан өнәгән. Кайбер җырларны, әйтемнәрне язып ала иде (аның блокнотлары архивта бүгенге көндә дә саклана), ә Сәмигулла абзыйныкын хәтеренә генә сеңдерде кебек.

Җыр-такмакларга килгәндә, әниебез дә әтигә тапкыр үрнәкләр бирә иде. «Ташкыннар»да аулак өйдә:

Бай абзыйның бакчасы,
Бакчасында мунчасы.
Үлмәсен дә, кайтмасын да —
Килеп торсын акчасы, —

дип җырлаган солдаткалар, такмак белән биеп җибәргәндә, «Бибибикә, Бизаһидә, Бану, Сылу, Шәрифә» дип әйтәләр. Бу юлларның текстка әни әйтүе буенча кертелүе миңа мәгълүм.

*Дүртенче үзенчәлек* — Т. Гыйззәтнең татар профессиональ музыкасына, бигрәк тә музыкаль драма һәм комедия жанрларына ясаган йогынтысы.

Билгеле булганча, Салих ага үзенең музыкаль драмаларга язган көйләре арасында иң камиле һәм профессиональ яктан иң югары дәрәҗәдә иҗат ителгәне дип Т. Гыйззәтнең «Наёмщик» әсәренә язган музыкаль көйләрен санаган… Бу турыда үзләренең истәлекләрендә Хәким ага Сәлимҗанов та, шулай ук Риза ага Ишморатов та язып калдырганнар. Әлеге фикерне музыка белгече Яков Гиршман да куәтли иде. Ә менә халкыбызның икенче сөекле композиторы Җәүдәт ага Фәйзи Т. Гыйззәт белән С. Сәйдәшев арасындагы бәйләнеш турында гаҗәеп дәрәҗәдә кыю фикер әйтеп калдырган: «Наёмщик» — С. Сәйдәшевне композитор буларак мәңгеләштергән әсәр! Увертюрасыннан башлап ахыргача «Наёмщик»та Сәйдәш күңеленең бөтен нечкә кыллары моңлана, дәртле йөрәк тибеше ишетелә, композиторлык таланты бөтен көченә яңгырый. Әйтерсең лә халык көйләре чылбыры белән бәйләп куелган юрга ат иске алымнар традициясе баганасыннан ычкынган да сөрелмәгән җирдән яңа юл салып чапкан. Рәхмәт Т. Гыйззәткә! Ул аны бу бәйдән ычкындырган!» (*Фәйзи Җ.* Халык җәүһәрләре… — Тө-